# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**“Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2013 елның 24 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында” 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2005, № 10 (I өлеш); 2007, № 10; 2008, № 11 (III өлеш); 2009, № 12 (I өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 7 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 5 пункт өстәргә:
“5) ике гражданлыкка ия затлар.”;

2) 15 статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $11^{2}$ пункт өстәргә:
“$11^{2}$) федераль законнар нигезендә Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы составына үз составыннан вәкил сайлау тәртибе;”;

3) $16^{1}$ статьяга түбәндәге эчтәлекле $2^{1}$ өлеш өстәргә:
“$2^{1}$. Иҗтимагый палата рәисе Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы составына сайланган очракта, ул Иҗтимагый палата рәисе вәкаләтләрен үз өстеннән төшерергә тиеш.”;

4) 20 статьяның 1 өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
“1. Иҗтимагый палатаның, Иҗтимагый палата Советының, Иҗтимагый палатаның структур бүлекчәләренең бәяләмәләр, тәкъдимнәр һәм мөрәҗәгатьләр рәвешендә кабул ителә торган карарлары тәкъдим итү төсмеренә ия.”.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2013 елның 6 ноябре
№ 85-ТРЗ